**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 сентябрь № 654

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2016 ел, 15 февраль, 91 нче; 2016 ел, 2 июль, 454 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар

белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6 нчы пунктның дүртенче абзацына «субсидия алучының ризалыгы» сүзләреннән соң «(устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән тыш, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерциячел оешмалардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков